**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Алькеевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки**
**муниципаль районы**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ Базарлы Матак авылы КАРАР**

2022 елның 25 июне 216№

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 25 апрелендәге 167 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләренең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022елның 06 июнендәге “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 28 мартындагы "Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында" 233 номерлы карары нигезендә расланган "Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында" 521 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 25 апрелендәге 167 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләренең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы авыл җирлекләре бюджетларына башка

бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә (Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 11 октябрендәге 349 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Башка бюджетара трансфертлар муниципаль район составына керүче, территорияләрендә һөнәри керемгә салым буенча хисап чорыннан соң килә торган айның 1 числосына Татарстан Республикасы бюджетына бурычлары булмаган җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итүгә бирелә.»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«6. Хисап аенда i муниципаль берәмлек (МТi) өчен башка бюджетара трансфертлар күләме билгеләнә:

а) i муниципаль район өчен түбәндәге формула буенча:

$$\text{МТi} = \sum_{j=1}^{n} \text{НПДj} ,$$

биредә:

n - әлеге Тәртипнең 2 пункты таләпләренә туры килә торган муниципаль район составына керүче авыл һәм шәһәр җирлекләре саны, хисап аена Татарстан Республикасы бюджетына үз территорияләрендә теркәлгән салым түләүчеләрдән һөнәри керемгә салым кергән территориядән;

НПДj - j-шәһәр, авыл җирлеге территориясендә теркәлгән салым түләүчеләрдән хисап аенда Татарстан Республикасы бюджетына кергән һөнәри керемгә салым суммасы, сум.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, салымнар һәм финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Әлки муниципаль районының
Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы: С.Н.Балакирев

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИНН 1606004118